РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

21.10.2019

№ 1247-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районынын жирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән муниципаль программага үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының, 2016 нчы елның 28 нче октябрендәге 1328-п номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының жирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән муниципаль программаны раслау турында"гы карары белән расланган. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының жирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән муниципаль программага, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында "Программаны финанслау күләмнәренең еллар һәм чыганаклар буенча бүленеше" юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2017 – 2022 нче елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабыннан финанслауның гомуми күләме 88 674,998 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2017 нче елда – 15 978,625 мең сум;<br>2018 нче елда – 15 136,410 мең сум;<br>2019 нчы елда – 14 259,963 мең сум;<br>2020 нче елда – 13200,000 мең сум;<br>2021 нче елда – 14 700,000 мең сум;<br>2022 нче елда– 15 400,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (Чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә ачыкланачак.<br>Экономияләнгән акчаларның калган өлешен ел саен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар үткәрү өчен җибәрергә. |

".

1.2. 3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудa булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән муниципаль программанын төп чаралары**

3 Таблица

| № п\п | Чаранын исеме | Башкаручылар (килешү буенча) | Финанслау күләме һәм чыганаклары (мен сум) | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Смета документларын эшләү | ТР Саба муниципаль районы җирлекләре башлыклары | Саба муниципаль районы бюджеты, Барлыгы 88 674,998, шул исәптән: 2017 ел-15 978,625; 2018 ел-15 136,410; 2019 ел-14 259,963; 2020 г – 13 200,000; 2021 г-14 700,000; 2022 г-15 400,000, әлеге программаның 4 нче таблицасында тәкъдим ителгән финанс чараларын бүлү буенча | агымдагы елның апрель - март айлары |
| 2 | Смета документларын тикшерү | “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчы хезмәте” МУП, ТР ФМ Саба районы ТОДК | | Тикшерүгә тапшырылган көннән соң 1 атна эчендә |
| 3 | Төзекләндерү эшләре үткәрү | Ачык аукцион нәтиҗәләре буенча электрон сатуларда (торги) җиңгән подрядчы оешма | | контрактта күрсәтелгән вакыт |
| 4 | Техник күзәтчелек һәм башкарыла торган эшләрнен сыйфатын контрольдә тоту | “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчы хезмәте” МУП | | эшләрне башкару барышында |
| 5 | Башкарылган эшләрне кабул итү һәм объектны файдалануга тапшыру | Заказ бирүче – (объектны балансга тотучы), Заказ бирүче-төзүче – “ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчы хезмәте “ МУП | | төзекләндерү эшләре тәмамланганнан соң |

”;

1.3. 4 нче таблицаны әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б.Таиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
1272-и 21.10.2019

карарына 1 кушымта

**2017-2022 елларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерүгә юл фондының финанс чаралары бүленеше**

4 Таблица

| № | ҖИРЛЕК ИСЕМНӘРЕ | Еллар буенча бүленеш (мең сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
| 1. | Саба ШҖ | 12769,409 | 14139,060 | 5393,281 | 12015,000 | | 5569,256 |
| 2. | Арташ АҖ | | | | | | 1956,364 |
| 3. | Олы Кибәче АҖ | 1073,112 | | | | 2786,858 | |
| 4. | Олы Нырты АҖ | | | | | | 2469,574 |
| 5. | Олы Шыңар АҖ | | | | | | |
| 6. | Курсабаш АҖ | 894,489 | | | | 3519,361 | |
| 7. | Югары Симет АҖ | | | | | | 2257,848 |
| 8. | Явлаштау АҖ | | | | | | |
| 9. | Эзмә АҖ | | | 3384,420 | | 2956,480 | |
| 10. | Иштуган АҖ | | | | | | |
| 11. | Килдебәк АҖ | | | | | | |
| 12. | Түбән Шытсу АҖ | | | | | | |
| 13. | Мишә АҖ | | | | 525,000 | | |
| 14. | Мичән АҖ | | | | | | |
| 15. | Олы Кибәче АҖ | 1241,615 | 997,350 | | | | 1245,857 |
| 16. | Иске Икшермә АҖ | | | | | | |
| 17. | Тимершык АҖ | | | | 660,000 | | |
| 18. | Шекше АҖ | | | | | 2785,442 | |
| 19. | Юлбат АҖ | | | | | 2651,868 | |
| 20. | Шәмәрдән АҖ | | | 5482,262 | | | 1901,101 |
| | БАРЛЫГЫ: | **15978,625** | **15136,410** | **14259,963** | **13200,000** | **14700,000** | **15400,000** |